КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 26 август № 623

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә гражданнар сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары структурасы турында» 2005 елның 28 апрелендәге ПУ-147 номерлы, «Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» Указына үзгәреш кертү хакында» 2015 елның 29 июлендәге ПУ-680 номерлы, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы структурасына үзгәреш кертү турында» 2015 елның 29 июлендәге ПУ-681 номерлы указларын үтәү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 23 декабрь, 1052 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 22 февраль, 128 нче, 2013 ел, 7 ноябрь, 860 нчы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

беренче абзацта «153» саннарын «152» саннарына алмаштырырга;

өченче абзацта «106» саннарын – «111» саннарына, «529 721 сум» сүзләрен – «553 490 сум» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «39 берәмлек» сүзләрен – «33 берәмлек» сүзләренә, «174 757» саннарын «150 789» саннарына алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2011 ел, 23 декабрь, 1052 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» 2013 ел, 7 ноябрь, 860 нчы карарының 1 пунктындагы өченче, бишенче һәм алтынчы абзацларны үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына законнар нигезендә әлеге карарның 1 пунктын гамәлгә ашыруны тәэмин иткән оештыру карарларын кабул итәргә.

4. Бу карарның көче 2015 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\623.docx